ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.10.2021 с. Введенская Слобода №5

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең
Восточная Звезда авылында гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче ст., Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 13 нче ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Восточная Звезда авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Восточная Звезда авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 нче елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- балалар мәйданчыгын төзекләндерү

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Восточная Звезда авылы, Грушевая урамы адресы буенча су башнясы янында 9:30 да үткәрергә.

4. Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетын халык җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе  авыл җирлеге
башлыгы Д.В. Морозов